| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.08.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2915** |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составындагы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составындагы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондын төзү, тоту тәртибен билгеләү, алардан файдалану турында хисап тоту максатларында , Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы, «Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 30 июлендәге 210 номерлы карары белән (2022 елның 24 мартындагы 159 номерлы үзгәрешләре белән) расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 сентябрендәге 2450 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составындагы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 п. сигезенче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Зеленодольск муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен биргәндә акчалата бүләкләүләр тапшыру»;

1.2. Нигезләмәнең 4 п. 4.7 п.п. түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«4.7 «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен биргәндә акчалата бүләкләүләр «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турындагы нигезләмәдә билгеләнгән күләмнәрдә түләнә».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин